ГЛАВА МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление

№ 1 — от “20” февраль 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгының 2012 елның 1 августындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокурорының 2023 нче елның 31 мартындагы 02-08-02-2023 номерлы протесты, "Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2022 елның 14 июлендәге N 270-ФЗ федераль законнар, Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгының 2012 елның 1 августындагы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында" 4 нче номерлы карарына (алга таба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге Карарга Кушымтаның 8.12 пунктында “Интернет челтәрендә” сүзләрен “рәсми сайтларда” сүзләренә алмаштырырга;

1.2 Әлеге Карарга Кушымтаның 9.6 пунктында "җирле үзидарә органнарының" сүзләрен “җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның" сүзләренә алмаштырырга, “хезмәткәрләр" сүзләреннән соң “ведомство карамагындагы оешмаларның хезмәткәрләре” сүзләрен өстәргә;

1.3 Әлеге Карарга Кушымтаның 6 пунктындагы 4 пунктчасында “җирле үзидарә органнары” сүзләреннән соң “һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.4 Әлеге Карарга Кушымтаның 3.1 пунктына “һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.5 Әлеге Карарга Кушымтаның 5.1 пунктындагы 4 пунктчасында "җирле үзидарә органнарының, аларның вазифаи затларының" сүзләрен “җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның, әлеге органнарның һәм оешмаларның вазифаи затларының" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Кече Кирмән авыл җирлеге башлыгы: Х.Х.Мубаракшин